**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**29.11.2023 ел** **№ 1818**

**«2024 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортта торак урыннар милекчеләренә торак урынны карап токан өчен түләү күләмен үзгәртүнең иң чик индексы турында»**

Россия Федерациясе торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләренә торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районында күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортта торак урыннар милекчеләренә 2024 елга торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын 9 % күләмендә расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http:/pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин